**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Оштырма Юмья авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**05 ноябрь 2020 ел** **№5**

**«Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Филипповка авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 17 ноябренә 12 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Филипповка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Филипповка авылы, Октябрь урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йортта гражданнар җыены үткәрү.

2. 2020 елның 17 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Филипповка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Филипповка авылы, Октябрь урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йортта гражданнар җыены үткәрү.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан туендыручысын югалткан күп балалы гаиләләрдән тыш кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Яңа Кумор авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Филипповка авылы юлларын ремонтлау ,проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, таш сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Филипповка авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан һәм территорияне җәйге чорда чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Оштырма Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.Г. Антонов